**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Кышлау авыл җирлеге Кызыл Утар торак пунктында**

## ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

“15” ноябрь 2022 ел. № 2

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлегенең Кызыл Утар торак пунктында халык җыены

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Кызыл Утар авылы территориясендә, 2023 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Кызыл Утар авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, тавыш бирү хокукына ия булган кешегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, 1 нче төркем инвалидлардан, мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

1) Кызыл Утар авылы территориясен чистарту (үлән чабу);
2) урам утларына хезмәт күрсәтү өчен түләү;
3) урамга яктырткычлар сатып алу;
4) балалар өчен уен җиһазларын сатып алу һәм урнаштыру (килешү буенча хезмәт хакы түләү).

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлегенең Кызыл Утар авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Кышлау авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4 Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Кызыл-Утар авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Кышлау авыл җирлеге башлыгы Кашшапов А.Х.

Кышлау авыл җирлеге Советы
ИНН 1610000620
ОГРН 1021606755372